ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының аерым комитетлары составларындагы үзгәрешләр турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты Анисимов Дмитрий Владимировичны Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Торак сәясәте һәм инфраструктура үсеше комитеты составына кертергә.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты Мөхәммәтшина Рима Җәмил кызын Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты составына кертергә.

3. «Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Торак сәясәте һәм инфраструктура үсеше комитетын сайлау турында» 2019 елның 20 сентябрендәге 16-VI ДС номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарының икенче абзацында (2021 елның 23 апрелендәге 944-VI ДС номерлы, 2021 елның 23 сентябрендәге 1131-VI ДС номерлы һәм 2021 елның 25 октябрендәге 1153-VI ДС номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) «10» санын «11» санына алмаштырырга.

4. «Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитетын сайлау турында» 2019 елның 20 сентябрендәге 20-VI ДС номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарының икенче абзацында «12» санын «13» санына алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ / АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре,
2022 елның 23 сентябре
№ 1571-VI ДС